МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

18.05.2020 г. Казань № 392-осн

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2014 елның 20 маендагы 188-осн номерлы боерыгына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2014 елның 20 маендагы 188-осн номерлы боерыгына үзгәреш кертеп, түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$. Әлеге боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән Исемлеккә туры китереп, керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру бурычын йөкли торган вазыйфаларны биләүче Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең мондый белешмәләрен, шулай ук аларның иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырырга.»

Министр Р.Ә. Кузюров